Мәкалә киң танылу алмаган шагыйрь Рәхим Саттарның тормыш һәм иҗат юлын яктырта, татар шигъриятендәге урынын билгеләп, әдәби барышта ул үстереп алып киткән традицияләрне ачыклый. Герменевтик якын килеп, шагыйрьнең тоткынлыкта язылган 24 шигыре беренче тапкыр фәнни нигездә анализлана, төп мотивлары билгеләнә, шигъри әсәрләрнең үзенчәлеге шул чор әдәби барышы контекстында ачыклана. Бу мәкаләнең яңалыгын һәм актуальлеген билгели. Тикшеренүнең төп максаты – Рәхим Саттарның тормыш һәм иҗат биографиясен өйрәнү, шигъри әсәрләрен киң фәнни әйләнешкә кертү. Мәкаләдә

шагыйрьнең биографиясенә, тоткынлыктагы язмышына караган гаиләсе архивында, ТР Милли музее архивында сакланган материаллар, истәлекләр, интервью материаллары файдаланыла. Эзләнүләр нәтиҗәсендә, Рәхим Саттарның сугыш чоры әдәбияты традицияләренә генә таянып калмыйча, поэтик яссылыкта экспериментлар алып баруы ачыклана. Тикшеренүләр барышында шагыйрь әсәрләренең жанр төрлелеге билгеләнә, аның әсәрләрендәге төп мотивлар буларак илгә тугрылыкны раслау, илне сагыну һәм тоткынлык аерып чыгарыла, бу яңарышның лирик герой концепциясе белән янәшәдә баруы тәгәлләштерелә. Төп мотивларны җиткерүдә кулланылган образ-детальләр, алымнар бәяләнә, шуның аша Р. Саттар әсәрләренең поэтик хасиятләре дә тәгаенләнә. Туган илгә тугрылыкны раслау темасы Р. Саттарның тоткынлык чоры иҗатында үзәк мотивны тәшкил итә. Бу мотив ант һәм ышаныч образлары, үлем-үлемсезлек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә булып, шагыйрь шәхесе белән Туган ил арасындагы мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Тугрылык мотивына мөнәсәбәтле шигырьләрдә ант образы көчле чагылыш таба, туган ил – табигать – туган җир – ана чылбыры кабатлана. Илне сагыну темасы белән сугарылган шигырьләрдә үз / чит каршылыгы үзәктә тора, Туган ил чит җиргә каршы куелып, бу төшенчә төрле образ-сурәтләр ярдәмендә гәүдәләнә. Тоткынлык мотивы алга чыккан шигырьләр фаҗигалелекнең көчле булуы белән характерлана.

**Төп төшенчәләр**: Рәхим Саттар, биография, сугыш чоры татар шигърияте, лирик герой, образ, жанр, мотив, әдәби алым

## Кереш

Татар әдәбияты шагыйрьләргә искиткеч бай, ләкин аерым әдипләр генә тирән һәм төрле яклап өйрәнелгән, бәяләнгән, күбесе әлегә кадәр үз тикшеренүчесен көтә. Иҗатлары тарих тузанына капланган бик күп әдипләрнең мирасын киң катлам халыкка кайтару, таныту, фәнни яссылыкта өйрәнеп, татар әдәбиятындагы урынын билгеләү бүгенге әдәбият белемендәге әһәмиятле бурычларның берсе булып кала. Мондый әдипләр арасында Рәхим Саттар (1912–1943) иҗаты да бар.

Рәхим Саттарның иҗат биографиясе сугыш алды һәм сугыш чоры татар әдәбияты контекстында үсә-үзгәрә. Чор шигъриятендә төп тема буларак сугыш темасы калкып чыга һәм төрле тематик яссылыкларда сурәтләнә. Чорга аваздаш төстә татар шигъриятендә яшәү һәм үлемгә мөнәсәбәт калкулана. Бу вакытта татар поэзиясендә актив булган яшәү / үлем, без / дошман, туган җир / чит җир, сугыш / тынычлык бинар оппозицияләре яшәү һәм үлем фәлсәфәсен җиткерүгә йөз тота. Лирик герой ил азатлыгы өчен көрәшкә чыккан, соңгы тамчы каны тамганчыга кадәр илен сакларга әзер кыю солдат булып конкретлаша. Совет мифының иң динамик, үзгәрүчән образы – герой архетипик образы агымдагы чор татар поэзиясендә герой-сугышчы, утлар-сулар кичеп чыккан Ватан солдаты кебек тәкъдим ителә. Бу чор шигъриятендә илне көрәшкә өндәү, җиңүгә ышаныч, дошманга нәфрәт һәм илне саклау хакында ант бирү мотивлары әйдәп бара [1, 212 б.]. Романтик буяуларда сурәтләнгән солдат халык авыз иҗатының әкият-дастаннарындагы сурәтләр, шартлы алымнар һәм тел чаралары ярдәмендә сурәтләнә.

Рәхим Саттар иҗаты да шушы контекстта үсә-үзгәрә, әмма шагыйрь үз әсәрләрендә башка алымнарны кулланып, үзгә образларны яңа мәгънә бөтенлекләрендә тәкъдим итеп, экспериментлар да ясап карый.

Әдәби барышта шагыйрьләр ике якка аерыла: аерым әдипләр яңарыш алып килеп, сүз сәнгате үсешендә яңа сукмаклар сала, икенче төркем авторлар шушы яңалыкларны дәвам итеп, үстереп алып китә, аларның традиция булып формалашуын, милли җирлектә үзләштерелүен тәэмин итә. Р. Саттар икенчесенә карый. Шагыйрьнең төп архивы – тоткынлык чорында язып калдырылган шигырьләр блокноты, язмалары – ТР Милли музее архивында саклана [2]. Шагыйрьнең татар телендә нибары биш төп басма китабы басылып чыккан [3], [4], [5], [6], [7]. Иҗаты һәм эшчәнлеге турында З. Исмәгыйлева [8], Н. Дәүли [9], Б. Камалов [10], Р. Мостафин [11], [12], Ш. Мостафин [13], [14], [15], И. Саттаров [16], [17], [18], [19], [20], [21], М. Шәрипов [22] кебек галим, тәнкыйтьче-публицистларның, әдипләрнең аерым мәкаләләре, истәлек-язмалары дөнья күрә. Әмма Рәхим Саттарның иҗаты моңа кадәр аерым монографик фәнни тикшеренүләрнең үзәгенә куелмаган. Бу факт әдип мирасының тиешенчә өйрәнелмәве, бу юнәлештәге эзләнүләрнең актуаль булуы турында сөйли.

**Хезмәтнең методологик нигезе**

Хезмәтнең методологик нигезе итеп герменевтик эзләнүләр алынды [23]. Методик яктан Б. Л. Борухов тәкъдим иткән «мотивлаштырылган поэтика» файдаланылды. Ул аңлатуны фәнни эшчәнлекнең ахыргы максаты буларак карый һәм әдәби текстны анализлау өчен төп метод итеп канун (закон) нигезендә аңлатуны аерып чыгара, аны текстны мотивацияләү дип атый [24]. Б. Л. Борухов мотивацияләүнең мәдәни, конвенциаль, менталь төрләрен аерып чыгара [24, 13 б.]. Рәхим Саттар иҗатын өйрәнү өчен, аның конвенциаль төре нигез итеп алынды. Галим әдәби күренеш булган текст һәр чорда үз закон һәм конвенцияләренә буйсынып дөньяга чыга дип билгели. Конвенциаль мотивацияләү шагыйрь иҗатының төп үсеш тенденцияләрен аерып чыгарырга, тоткынлык чоры шигырьләрендә әдәби традицияләрнең дәвам ителешен ачыкларга яки аларның трансформациясен, яңарыш юлларын, аларның нигезен, үзенчәлеген аңлатырга мөмкинлек бирә.

**Фикер алышу**

Рәхим Саттар 1912 елның 15 августында хәзерге Башкортстан Республикасы Чишмә районы Түбән Хаҗәт авылында туа. Әтисе Сөләйман белән әнисе Хәдичә үз чоры өчен шактый укымышлы, укый-яза белгән дини кешеләр була, әтисе авылда мулла вазифасын үти. Киләчәккә карап эш итә белгән, зирәк акыллы гаилә башлыгы 7 баласының да дөньяви белем алуларын тели һәм укыта.

Рәхим Саттар кечкенәдән үк әдәбиятка гашыйк булып үсә, дүртенче сыйныфта укыганда ук, тәүге шигырьләрен яза башлый [25, 325 б.]. Авылдагы мәктәпне тәмамлагач, укуын дәвам итү өчен, ул Уфа шәһәренә юнәлә, нәкъ менә биредә, 2 нче урта мәктәптә белем алганда, укытучы Нәкый Исәнбәт белән таныша. Бу очрашу киләчәге әдәбият дөньясы белән тыгыз бәйләнәчәк Рәхим Саттар өчен хәлиткеч була. Үзе дә әдәбиятка гашыйк, талантлы Исәнбәт балада булган сәләтне тиз күреп ала, аны ачуга, үстереп җибәрүгә зур көч куя, алга таба да Рәхимгә даими рухи көч биреп тора.

Укуын тәмамлаганнан соң, Рәхим Саттар Донбасс шахталарында, туган төбәгендә төрле эшләрдә дә хезмәт куя. 1932 елда өйләнеп, 1933 елда Армиягә алына һәм 1937 елга кадәр Байкал чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә, әмма иҗатны бервакытта да ташламый. Шул елларда Башкортстан һәм Татарстан көндәлек матбугатында аның яшьлек хисләре белән өретелгән беренче лирик парчалары басылып чыга. 1937 елда ул Казанга күчеп килә һәм төрле вазифалар башкара: тулай торакта комендант та була, аннан Мәгариф халык Комиссариатының урта мәктәпләр бүлегендә кадрлар буенча белгеч (1938 елның февраленнән) булып эшли, ә өч айдан педагогик кадрлар буенча баш инспектор итеп куела (1938 елның 1 маеннан 1939 елның 15 маена кадәр), шушы вакытта Татар педагогия институтына укырга керә. 1939 елның 17 маеннан «Кызыл яшьләр» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясенә әдәби хезмәткәр булып күчә. Газета-журналлар белән тыгыз элемтәдә тору, Ш. Маннур, С. Хәким, Ә. Фәйзи, Ш. Камал, Г. Хуҗи, Г. Кутуй, Х. Туфан, Г. Кашшаф, Г. Халит, Н. Дәүли, Ш. Мөдәррис кебек әдипләр белән тыгыз аралашу аның иҗатына уңай йогынты ясый, сан һәм сыйфат ягыннан үстерә. Иҗатының беренче чоры буларак бәяләнүгә лаек булган кыска гына вакыт аралыгында очерк, мәкалә, әдәби тәрҗемә, хикәя, шигырь жанрларында 60тан артык язмасы дөнья күрә, шулар арасыннан 12се шигырьгә карый. Бу Рәхим Саттарның иҗат активлыгы хакында сөйли. Шагыйрьнең әлеге чор әсәрләре шул дәвер яшь әдипләренең яңа сәнгать тудыру юлында ясаган тәҗрибәләренә аваздаш: илдәге яңарышка ихластан ышанган каләм иясе азатлык өчен көрәшкә, яңа тормышка дан җырлый, искене җимерү фәлсәфәсен уздыра.

Совет чоры әдәбиятында хезмәт, сыйнфыйлык һәм тигез тормыш төзү идеясе төп кыйммәтләрдән санала, батырлык культы алга сөрелә. Илнең төп яшәү рәвеше булып көрәш, яңа тормыш төзү темасы кызыл җеп булып сузыла, шуңа бәйле төстә сүз сәнгате дә бәхет яңа тормыш төзүдән гыйбарәт дип исбатларга тиеш була. Башка татар әдипләре кебек үк, Рәхим Саттарның яңа системага хезмәт итүче образларын үзәккә куйган, иҗтимагый тормыш белән нык бәйләнгән башлангыч чор иҗаты шундый фикерләр белән сугарыла.

Әдипкә, кызганычка каршы, иҗади сәләтен ахыргача ачып җиткерергә насыйп булмый. 1939 елда Фин сугышы игълан ителүгә, ул үз теләге белән фронтка китә, чаңгычылар отрядында командир дәрәҗәсенә күтәрелә. 1940 елның 1 апрелендә кабат Казанга кайтып, тыныч тормыш шартларында эшләүгә күчә: 1941 елның 15 июлендә «Кызыл яшьләр» газетасының җаваплы мөхәррире итеп билгеләнә.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, ул шул җәйдә үзе теләп Куйбышев хәрби училищесына китә, алман телен өйрәнүгә керешә. 1941 елның 15 октябрендә сугышка алына, профессиональ десантчы һәм шушы юнәлештә офицер дәрәҗәсен алган хәрби булуына карамастан, парашютистлар курсына җибәрелә. Десантчы сыйфатында, фашистлар тылында үткәрелгән күп кенә сугышчан операцияләрдә катнаша. Әмма 1942 елның маенда аның белән элемтәләр өзелә, Татарстанның Яңа Кади авылындагы гаиләсенә Рәхим Саттарның шушы елның 27 июнендә Смоленск тирәсендә хәбәрсез югалуы хакында хәбәр генә килеп ирешә.

Чынлыкта хәрби операцияләрнең берсендә чолганышта калып, Р. Саттар фашистлар кулына эләгә һәм, берничә ай Смоленск, Борисов шәһәрләрендәге хәрби әсирләр лагерьларында газап чиккәннән соң, 1942 елның 16 сентябрендә Берлин янындагы Вустрау лагерена озатыла, соңрак бирегә Муса Җәлилне китерәләр. Шул ук елның 13 декабрендә аларга Абдулла Алиш, Фуат Булатов, Гариф Шабаев килеп кушыла, әнә шулай, язмыш тәкъдире аркасында, татарның талантлы уллары – бар көч-куәтен татар мәдәниятенең, әдәбиятының алгарышына сарыф итәргә тиешле яшьләр – чит җирләрдә бергә туплана. Шунда әдип Абдулла Алиш белән якыная, Вустрау лагеренда вакытта яшерен оешмага кереп, Муса Җәлил һәм аның иптәшләре тарафыннан оештырылган әлеге яшерен антифашистик оешманың ышанычлы членнарыннан берсе булып китә, үз артыннан Фуат Булатов, Гариф Шабаевларны да ияртә. Рәхим Саттарның әсирләр лагеренда һәм мәгълүм «Идел-Урал» легионында гитлерчыларга каршы листовкалар язуда һәм аларны бастырып таратуда актив катнашуы билгеле.

1943 елның гыйнварында Р. Саттарны, А. Алиш, Ф. Булатов, Г. Шабаев белән бергә, «Идел–Урал» газетасы редакциясендә эшләү максатыннан, Берлинга күчерәләр. Бу әдип өчен яңа мөмкинлекләр ача, ул үзенең язмаларында, хикәя-шигырьләрендә, эзоп теле аша, Совет Армиясенең уңышлары хакында сөйли, Туган иленең уңышлары өчен шатлыклары белән уртаклаша, әнә шулай ил азатлыгы өчен көрәштә мылтыгы тартып алынган Рәхим Саттар үзенең көрәшен каләме белән дәвам итә. Дошман тылында барган әлеге хәрәкәт әдипнең батырлыгын тагын бер кат дәлилли. Исән кайткан легионерлар аның баракларга килеп йөрүе, әсирләр арасында яшерен оешма идеяләрен таратуы хакында сөйли. Документларга нигезләнсәк, «Патриот» дип аталган яшерен оешманың поляк партизаннары белән элемтә оештыруында, «Искра» яшерен оешмасы белән бәйләнешләрне ныгытуында да Р. Саттарның роле хәлиткеч була. Соңрак табылган Шәфи Алмасның Рәхим Саттар өстеннән язган доносы да бу фактларның хак булуын раслый [26], [27, 43 б.]. Ш. Алмас үзенең доносында түбәндәге фактларны китерә: большевикларның татар әсирләренә бирешмәскә, көрәшергә өндәп, март аенда язган яшерен хатында Г. Тукай шигырьләре файдаланыла, Р. Саттар да «Идел-Урал» газетасында Г. Тукайның нәкъ шул юлларына таянып мәкалә язды; 2) редакция хезмәткәре белән берлектә Казанның үсеше, анда Ленинның роле турында мәкалә бастырды; 3) татарларны немецларга пленга бирелергә чакырып язган листовкаларны таратудан баш тартты [20, 39 б.].

1943 елның август аенда яшерен оешма фаш ителеп, җәлилчеләрне кулга алганда, алар исемлегендә Р. Саттар да була. Шуңа да Ш. Мостафинның Рәхим Саттарны уникенче җәлилче дип атавында тулы хаклык бар [28]. Ләкин Р. Саттар 1943 елның июнь аенда лагерьдан качып өлгерә һәм билгесез югала. Дөресрәге, Рәхим Саттар җитәкләгән төркем алдына бурыч куела: М. Җәлил тәкъдиме нигезендә, алар фронт линиясен үтеп, үзебезнекеләр ягына чыгарга [22], аерым мәгълүматларга караганда, «Идел-Урал» легионында яшерен оешма төзелүе һәм легионерларның кораллы восстаниесе әзерләве турында совет гаскәрләренә хәбәр итәргә тиеш була. Әлеге качуны оештыручыларның берсе, әсир Әмир Үтәшев 1943 елның августында Рәхим Саттар җитәкләгән биш кешелек төркемнең Едлино лагереннан качуы турында сөйли. Әлеге төркемгә, Рәхим Саттардан тыш, Әкрәм Мәмлиев (Башкортстан), Гомәров (Казахстан, радист), Курышов (Барнаул өлкәсе), Әхмәт Шәрипов керә [29]. Рәхим Саттарның шуннан соңгы язмышы билгесез, бары тик аерым мәгълүматлар гына яши. «Муса» романын язу барышында Шәйхи Маннур Едлинога барып чыга һәм Рәхим Саттар язмышы турында сораша. Аңа урманчы полякның әлеге төркемгә качарга ярдәм итүе, урман эчендәге яшерен сукмаклар аша әсирләрне Варшавага кадәр озата баруы турында сөйли. Соңыннан ул полякны дошманнар кулга ала һәм җәзалап үтерә, ә

Рәхим Саттар төркеме засадага эләгә һәм печән кибәне астында яшеренеп торган вакытта фашистлар тарафыннан тереләй яндырып үтерелә [20, 34 б.].

Тоткынлык чоры әдәби эшчәнлеге Рәхим Саттарның икенче чор иҗаты буларак бәяләнергә лаек. Аның Борисов, Вустрау, Радом һәм Берлиндагы хәрби әсирләр лагерьларында иҗат иткән 24 шигыре М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» язмышын кабатлый. Шагыйрь махсус задание белән китәр алдыннан, ягъни лагерьдан качар алдыннан, үзенең шигырьләрен Абдулла Алишка тапшырып калдыра. Сугыш тәмамлангач, 1945 елда, әлеге табылдыкны үзе дә әсир булган Равилә Агеева Донбасска алып кайта һәм КПССның Донецк өлкә комитетына тапшыра, бу әсәрләрнең шуннан соңгы 19 еллык язмышы әлегә билгесез булып кала, алар бары 21 елдан соң – 1964 елда гына татар укучысына килеп ирешә. Әлеге җыентыкның тышына түбәндәге мәгълүматлар язылган: «Рәхим Саттаров, әсирлектә язылган шигырьләр. Смоленск – Борисово – Вустрау – Радом – Берлин. 1942–1943» [30].

Җыентыктагы шигырьләрнең 5се генә күңел лирикасына мөнәсәбәтле булып, калганнары гражданлык лирикасы жанрында иҗат ителгән. Аларда төп мотивлар буларак илгә тугрылыкны раслау, илне сагыну һәм тоткынлык аерылып чыга.

Туган илгә тугрылыкны раслау мотивы Р. Саттарның тоткынлык чоры иҗатында үзәк мотивны тәшкил итә. Тоткынлыктан кайткан блокнотында сакланып калган улына, хатынына һәм әнисенә атап язган язмасында да: «Илгә тугрылыклы булып калам! Мин хыянәтсез. Син дә шулай ук тугрылыклы бул! Юл бер генә. Башка юл юк» [30], дип раслаган шагыйрь өчен, күрәсең, тугрылык иң төп кыйммәтләрнең берсе булып саналган. Шигырьләрендә бу тема ант һәм ышаныч образлары, үлем-үлемсезлек төшенчәләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә, алар шагыйрь шәхесе белән Туган ил арасындагы мөнәсәбәтне ачуда төп чарага әверелә. Билгеле булганча, сугыш чоры татар поэзиясендә әлеге фикерләр, нигездә, үзенчәлекле лирик герой аша җиткерелә: Ватан азатлыгы өчен үлем үлемсезлеккә, үлгәннән соң яшәүгә (азатлыгы өчен үлгәннәрне Туган ил бервакытта да онытмас, халык йөрәгендә мәңге яшәр гыйбарәсе шуңа тоташа) юл алу буларак кабул ителә, нәкъ менә шул яссылыкта үлем яшәү белән тигезләшә [1, 211 б.]. Әмма Рәхим Саттар бу тип лирик геройның үзгә вариантын тәкъдим итә, аның шигырьләрендә яшәү – үлем – үлемсезлек янәшәлеге яңа мәгънә бөтенлегендә урын таба. Гомумән, мондый вариант сугыш чоры татар поэзиясендә актив түгел. Бу Р. Саттарның шагыйрь буларак үз юлын эзләвен, үз сукмагын салырга омтылуын күрсәтә. Шагыйрьнең «*Ут кабынмый яшен яшеннәми / Корбан бирми - халык яшәми*», «*һәр сулышым, / Барлык көчем / Синең өчен, Туган илем, / Синең өчен!*» [30] дип раслаган лирик герое, башка күп татар шагыйрьләре кебек, үлемне үлемсезлеккә илтүче, халык күңелендә яшәтүче чара буларак кабул итүдән бигрәк, аны халык бәхете, аның киләчәге хакына корбан бирү буларак раслый. Бу яктан ул татар фольклорында яшәп килүче корбан бирү мотивын тергезеп җибәрә. Р. Саттарның лирик герое эчке хөрлеген саклаган, көчле холыклы лирик герой булып күтәрелә. Аны сурәтләү юлында шагыйрь тарафыннан коллык / хөрлек каршылыгы оста файдаланыла (М. Җәлилдә, мәсәлән, ирек / коллык каршылыгы актив):

*Кулда богау, капка йозакта,*
*Ләкин рухым иркен, хөр кала* [30].

Тугрылык мотивына мөнәсәбәтле шигырьләрдә ант образы көчле чагылыш таба. «Ата һәм бала», «Ант», «Әнкәм» кебек шигырьләрендә туган илгә тугрылыгын раслау юлында шагыйрь туган иленә, халкына, әнисенә, әтисенә ант бирү хакында сөйли башлый. Кеше өчен иң кадерле, газиз кешеләргә ант бирү тугрылыкны көчәйтү чарасына әверелә, аны иң югары кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрә. Шушы юлда, М. Җәлил иҗатындагы кебек үк, биленә кылыч таккан батыр егете схемасы пәйда була. Мәсәлән, «Әнкәм» шигырендә әкияттәгечә биленә кылыч тагып, дошман каршына чыгып баскан егет илгә тугрылыкның изге көрәш булуын көчәйтүгә юнәлтелә, ил өчен бирелгән антны данлауга хезмәт итә. Чишмә, болын, җил, кош, көрәшче–егет образын тудыручы детальләр төсендә кылыч, ат кебек танылa торган берәмлекләр, милли–мифологик образлар лирик геройны сурәтләүдә фольклор традицияләрен көчәйтә. Шушы юлда, М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» циклына аваздаш төстә, Ананы мифлаштыру күренеше, туган ил – табигать – туган җир – ана чылбыры пәйда була.

Фольклордан, халык җырларыннан үстерелә килгән образларны куллану туган илне сагыну мотивына мөнәсәбәтле шигырьләрдә дә

актуальлеген югалтмый. Мондый шигырьләрдә өч үзенчәлек күзгә ташлана: 1) үзгә дөнья сурәте формалаша; 2) үзенчәлекле поэтик стиль алга чыга, әдип милли поэзиянең күптөрле традицияләренә – классик әдәбият һәм халык иҗатында чарланган формаларга таяна (мәсәлән, «Парчалар»); 3) лирик геройның сагынуы иң газиз кешеләренә – әнисенә, сөйгән ярына – мөрәҗәгате аша көчәйтелә (мисал өчен, «Бер сүзең»). Рәхим Саттарның илне сагыну темасы белән сугарылган шигырьләрендә үз / чит каршылыгы көчле чагылыш таба, Туган ил чит җиргә каршы куелып, туган ил төрле образ-сурәтләр аша гәүдәләнә. Мисал өчен, «Уй кисәкләре» шигырендә каз бәбкәсе, яшел чирәм, каен, табигать тавышлары кебек романтик образ-детальләр туган илнең билгеләре булып күтәрелә, алар аша туган ил изге җир, бәхет чыганагы кебек сурәтләнә. Соры төс, томан кебек образлар исә чит җирнең ямьсезлеген ачуга юнәлтелә:

*Соры урам. Соры биналар.*
*Соры һава. Соры болытлар.*
*Бар да соры, төссез, күңелсез,*
*Яктырталмый аны зур утлар* [30].

Туган иленнән читтә булган лирик геройның язмышын ачу юлында әнкәсен югалткан бәбкә образы ярдәмгә килә, шушы юлда шагыйрь кабат туган ил – Ана мифологик чылбырын тергезә һәм, туган илнең кеше өчен Ана кебек изге һәм кадерле булуын, аны сагынуның да шундый ачы икәнлеген төгәлләштереп куя:

| | |
|---|---|
| *Кирәк түгел миңа манарасы,* | *Токмач булсын, тары өйрәсе,* |
| *Кирәк түгел матур сарайлар.* | *Кәләпүшле булсын бабасы.* |
| *Кирәк түгел яшел юл арасы,* | *Тездән баткак булсын юлында,* |
| *Кирәк түгел миңа күк-айлар.* | *Сөял ярылып ятсын кулында,* |
| *Салам булсын өйнең түбәсе,* | *Тик Туган ил булсын, Туган ил,* |
| *Яланаяк йөрсен баласы,* | *Мин илемә үскән батыр ир* [30]. |

Бу юнәлештәге аерым шигырьләр халык җырлары стилен, халык җыры үлчәмен яңарта, мисал өчен, «Парчалар» шигырендә шундый үзенчәлек күзгә ташлана.

Тоткынлык мотивы «Әсирләр», «Чүлләр» кебек шигырьләрдә алга чыга, мондый әсәрләрдә фаҗигалелек көчле. Мисал өчен, «Чүлләр» шигырендә чүл сурәте тоткынлык язмышына гына түгел, фашизм коллыгына төшкән алман иленә дә бәя бирә башлый. Сусыз, комнан башка берни калмаган чүл күренеше, бер яктан, илсез калган тоткыннарның, икенче яктан, фашизм коллыгына төшкән алман халкының эчке бушлыгын, хыял-омтылышларсыз чынбарлыгын ачып җибәрә:

| | |
|---|---|
| *Бушлык. Үлем. Тынлык һәм сулышсыз* | *Нурлар - кайнар. Сары комнар.* |
| *Иңрәп ята җирдә киң чүлләр.* | *Җир аркасы пешә, ут булып.* |
| *Урман да юк, сыңар яфрак та юк,* | *Бер тамчы дым бирми, күзен салмый,* |
| *Елгалар да анда юк, күлләр.* | *Читтән генә үтә күк болыт* [30]. |

Сугыш чоры шигъриятендә актив булмаган бу образны үзенчәлекле мәгънә яссылыкларында сурәтләве шагыйрьнең тоткынлык шартларында да эзләнүләр алып баруы, поэтик экспериментлар ясавы хакында сөйли.

**Төп нәтиҗәләр**

1. Рәхим Саттар, үзенчәлекле тормыш юлы үтеп, токынлык язмышы белән Җәлил батырлыгын кабатлаган шәхесләрнең берсе буларак бәяләнүгә лаек.

2. Р. Саттарның тоткынлык чоры иҗатында барган эзләнүләр, эчтәлек ягыннан бигрәк, поэтик образлылык һәм шәхес концепциясе бирелешендә көчле булып, сугыш чоры шигъриятен яңарта.

3. Р. Саттарның тоткынлыкта язылган шигырьләренең 5се генә күңел лирикасына мөнәсәбәтле булып, калганнары гражданлык лирикасы жанрында иҗат ителгән. Аларда төп мотивлар буларак илгә тугрылыкны раслау, илне сагыну һәм тоткынлык аерылып чыга.

4. Шагыйрьнең лирик герое үлемне үлемсезлеккә илтүче, халык күңелендә яшәтүче чара булудан бигрәк, халык бәхете, аның киләчәге хакына корбан бирү буларак бәяли. Бу яктан ул татар фольклорында яшәп килүче корбан бирү мотивын яңарта.

5. Тугрылык мотивына мөнәсәбәтле шигырьләрдә ант образы көчле булып, туган илгә тугрылыгын раслау юлында шагыйрь туган иленә, халкына, әнисенә, этисенә ант бирү хакында сөйли. Кеше өчен иң кадерле, газиз кешеләргә ант бирү тугрылыкны көчәйтү чарасына әверелә, аны иң югары кыйммәт дәрәҗәсенә күтәрә. Шушы юлда Ананы мифлаштыру күренеше, туган ил – табигать – туган җир – ана чылбыры кабатлана.

6. Туган илне сагыну мотивына мөнәсәбәтле шигырьләр өч үзенчәлек тирәсенә туплана: үзгә дөнья сурәте, үзенчәлекле поэтик стиль, лирик герой сагынуының иң газиз кешеләренә – әнисенә, сөйгән ярына – мөрәҗәгате аша көчәйтелүе.

## Йомгак

Шул рәвешле, Рәхим Саттар 24 шигыре белән дә сугыш чоры татар шигъриятенә яңалык алып килә. Әдәбиятка яңа тормыш төзү хакындагы олы бер миф тудырылган вакытта килгән шагыйрь халык авыз иҗатына, классик шигъри традицияләргә мөрәҗәгате аша татар шигъриятен яңарту юлларын эзли. Бу юлда Р. Саттарга үзе дә шушы юнәлештә актив эзләнүләр алып барган, халык авыз иҗатына мөрәҗәгате белән хәтта XX гасырның икенче яртысы татар шигъриятендәге милли нигезләргә әйләнеп кайту процессына нигез салган М. Җәлилнең йогынтысы көчле була. Әмма вакытсыз өзелгән гомер бу талантның тулысынча ачыла алмый калуына китерә. Бу урында шагыйрьнең үз шигъри юлларын кабатлыйсы килә:

*Өзелеп калды ул җыр, бүленеп калды*
*Тавышы күтәрелгән чагында* [30].

**Әдәбият**


1. *Йосыпова Н.М.* Поэзия // Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. Т. 5: 1917–1956 еллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. Б. 190–219.
2. Рәхим Саттар коллекциясе: Папка 1, ТР ММ КП – 24898(1–41), КП – 38497 (1–3), В – 24888 (1–2); Папка 2 ТР ММ КП – 39308 (1 – 12), В – 25068 (1–2).
3. *Саттар Р.* Җыр дәвам итә. Шигырьләр. Казан: Тат. кит. нәшр., 1966. 64 б.
4. *Саттар Р.* Бүленгән җыр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 153 б.
5. *Саттар Р.* Безнең буын. Казан, 2006. 102 б.
6. *Саттар Р.* Рухым гали. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 95 б.
7. *Саттар Р.* Тоткынлыкта. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 133 б.
8. *Исмәгыйлева З.* Бүленгән җыр ялганырмы? (Җәлилче Р. Саттар турында) // Татарстан яшьләре. 2004. 12 октябрь.
9. *Дәүли Н.* Мусалар дивизиясеннән солдат кайтты // Н. Дәүли. Ак янында кара: Әдәби тәнкыйть, публицистик мәкаләләр, очерклар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. Б. 84–87.
10. *Камалов Б.* Җәлилче батыр (Р. Саттар турында) // Социалистик Татарстан. 1969. 7 январь.
11. *Мостафин Р.* Президент доносы (Р. Саттар турында) // Татарстан яшьләре. 1969. 9 январь.
12. *Мустафин Р.* Поэзия в солдатской шинели // Советская Татария. 1979. 13 май.
13. *Мостафин Ш.* Уникенче каһарман (җәлилче Р. Саттарның тууына 100 ел) // Мәдәни җомга. 2012. 24 август.
14. *Мостафин Ш.* Уникенче батыр // Мәйдан Чаллы. 2017. № 10. Б. 127–144.
15. *Мостафин Ш.* Мәңгелек ут чаткысы (Р. Саттар турында) // Алар – Җәлил-Кормаш йолдызлыгыннан!.. Казан: «Сүз» нәшр., 2017. Б. 147–158.
16. *Саттаров И.* Төштә генә күргән кебек... // Ватаным Татарстан. 1992. 21 август.
17. *Саттаров И.* Долгое возвращение: Версия сына о судьбе отца // Советская Татария. 1992. 22 август.
18. *Саттаров И.* Әтием әсәре... // Казан утлары. 1996. № 2. Б. 155–157.
19. *Саттаров И.* Әтиемнән мин дә хатлар алдым... // Мәдәни җомга. 1997. 19 сентябрь.
20. *Саттаров И.* Завещание. Об отце // Казань. 1998. № 5–6. С. 34 – 43.
21. *Саттаров И.* Разговор с отцом // Казань. 2000. № 5. С. 30–34.
22. *Шарипов М.* Прерванная песня: Неизвестные страницы жизни поэта-героя Рахима Саттара, члена подпольной антифашистской организации военнопленных // Культура. 2012. 2 октября.
23. Терминология современного зарубежного литературоведения. (Страны Западной Европы и США) / отв. ред.: Ильин И.П., Цурганова Е.А. М.: ИНИОН, 1992. 218 с.
24. *Борухов Б.* Введение в мотивирующую поэтику // Филологическая герменевтика и общая стилистика. Тверь: Изд-во Тверского ун-та, 1992. С. 5–28.
25. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда. Т 2. Казан: Татар.кит.нәшр., 2009. Б. 325–326.
26. *Мостафин Р.* Президент доносы // Социалистик Татарстан. 1969. 7 декабрь.
27. *Саттар Р.* Завещание. Казань, 2004. 112 с.
28. *Мостафин Ш.* Уникенче каһарман (җәлилче Р. Саттарның тууына 100 ел) // Мәдәни җомга. 2012. 24 август.
29. Дополненная биография Рахима Саттара / Личный архив семьи Саттаровых.
30. *Саттар Р.* Тоткынлыкта (1942–1943): блокнот / ТР ММ архивы: КП – 24898.

# ПРИМЕР ГЕРОИЧЕСКОГО ПОДВИГА: ТВОРЧЕСТВО РАХИМА САТТАРА

**Нурфия Марсовна Юсупова**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

В статье систематизированы сведения о жизненном и творческом пути поэта Рахима Саттара, чье творчество незаслуженно забыто; предпринята попытка определить его место в татарской поэзии, традиции, которые он развил в литературном процессе. Материалом для анализа послужили 24 стихотворения, написанные в плену. Данные произведения проанализированы с помощью герменевтического метода в контексте литературного процесса того времени. В ходе исследования определены основные мотивы. Это определяет новизну и актуальность статьи. Цель исследования – изучение жизненного и творческого пути Рахима Саттара, введение в широкий научный оборот его поэтических произведений. В статье использованы материалы, воспоминания, интервью поэта, относящиеся к его биографии, судьбе в заключении, хранящиеся в архиве его семьи, Национальном музее РТ. В ходе исследования удалось доказать, что Рахим Саттаров творил в русле традиций литературы военного времени, а также не боялся поэтических экспериментов. Произведения поэта отличаются жанровым богатством. Основным мотивом лирики становится идея преданности Родине, тоска по ней в плену. Мы становимся свидетелями обновления концепции героя. Эстетические ориентиры поэта определяются на основе анализа образов-деталей, поэтических приемов. В творчестве поэта периода плена ключевым становится стремление доказать свою преданность Родине. Эта идея находит воплощение в образе поэта и Родины, а также через категории смерть-бессмертие, клятва-вера. В стихотворениях о преданности большое место отводится мотиву клятвы, о Родине – образам природы, родной земли, матери.

В стихотворениях о тоске по Родине важно место занимают антитезы родное – чужое, Родина – чужбина. Стихи периода плена полны драматизма.

**Ключевые слова**: Рахим Саттар, биография, татарская поэзия военной поры, лирический герой, образ, жанр, мотив, поэтические приемы